**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4569**
**14.09.2020**

Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм
бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын
тәэмин итү комиссиясе турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы карары, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба - комиссия) турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча;

2) комиссия составын 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 14 сентябрендәге
4569 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба - комиссия) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системаның (алга таба - ГТХТС) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, булдырмау, шәһәр территориясендә зыян һәм тискәре нәтиҗәләр күләмен киметү һәм шәһәр оешмаларында гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра.

2. Комиссия даими эшләүче орган булып тора, үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шәһәр Уставына таяна.

3. Комиссия үз эшчәнлеген Башкарма комитет Җитәкчесе - шәһәрнең гражданнар оборонасы җитәкчесе җитәкчелегендә гамәлгә ашыра.

4. Комиссиянең үз исеме язылган бланкы бар.

2 бүлек. Комиссиянең төп бурычлары һәм хокуклары

5. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен тормышка ашыру буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнашу;

2) халыкны һәм шәһәр территориясен гадәттән тыш хәлләрдән һәм янгыннардан саклау өлкәсендә максатчан программаларны эшләү һәм тормышка ашыру;

3) ГТХТС идарә органнары һәм шәһәр звеносы көчләре эшчәнлеген координацияләү;

4) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары һәм шәһәр оешмалары белән үзара хезмәттәшлекне һәм килешеп эшләүне тәэмин итү;

5) гадәттән тыш хәлләрне һәм янгыннарны кисәтү өчен билгеләнгән һәм бүлеп бирелә торган идарә органнарының, көчләрнең һәм чараларның эш итүләргә әзерлеген тәэмин итү;

6) гражданнар оборонасы, янгын куркынычсызлыгы буенча чаралар үткәрүне тәэмин итү, гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән һәм янгыннардан саклау планнарын эшләү һәм тормышка ашыру;

7) әйләнә-тирә табигый мохитнең һәм потенциаль куркыныч объектларның торышын күзәтүне һәм контрольдә тотуны, гадәттән тыш хәлләрне фаразлауны оештыру;

8) гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын үткәрү турында карар кабул итү һәм шәһәр территориясендә аларны үткәрүне оештыру;

9) эвакуациягә әзерлек чараларын үткәрү, халыкны һәм матди-мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләүне планлаштыру һәм оештыру, эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыру һәм гадәттән тыш хәлләр бетерелгәннән соң аны даими яшәү урыннарына кире кайтару;

10) гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру, урнаштыру, саклау һәм тулыландыру;

11) гадәттән тыш хәлләрдә, булган чаралар чикләрендә авария коткару һәм башка кичектергесез эшләр оештыру һәм үткәрү, шулай ук аларны үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклау;

12) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча эш итү планын эшләү һәм тормышка ашыру, гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча эшләрне оештыру һәм контрольдә тоту, эшкә яраклы халыкны тискәре нәтиҗәләрне бетерүгә һәм җимерекләкләрне торгызуга җәлеп итү;

13) шәһәр территориясендә профессиональ авария-коткару хезмәтләре, авария-коткару формированиеләре булдыру;

14) су объектларында таләпләргә һәм нормаларга туры килә торган массакүләм ял итү, коену урыннары, коткару постлары урнаштыру, тиешле спорт мәйданчыкларын һәм корылмаларын үстерү һәм төзекләндерү;

15) Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Яр Чаллы инспекторлык бүлеге һәм санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашыручы тиешле органнар белән килешү буенча шәһәр сулыкларында ярышлар, бәйрәмнәр һәм республика, шәһәр әһәмиятендәге башка массакүләм чаралар үткәрү өчен урыннар билгеләү;

16) коткару постларын булдыруны һәм аларның эшен тәэмин итәргә;

17) гражданнар оборонасы максатларында азык-төлек запаслары, индивидуаль саклану медицина чаралары һәм башка чаралар булдыру, аларны карап тоту һәм саклау;

18) кешеләрне, әйләнә-тирә мохитне, мөлкәтне һәм мәдәни кыйммәтләрне куркыныч янгын факторларыннан коткаруга, шулай ук янгыннарны бетерүгә һәм авария-коткару эшләрен үткәрүгә юнәлдерелгән оператив-техник һәм инженерлык-техник чараларны гамәлгә ашыру;

19) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә муниципаль норматив-хокукый актлар әзерләү;

20) Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне һәм янгыннарны кисәтү һәм бетерү комиссияләре, хәрби командалык һәм иҗтимагый берләшмәләр белән гадәттән тыш хәлләрне һәм янгыннарны кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек, ә кирәк булган очракта - гадәттән тыш хәлләрне бетерү комиссияләренә ярдәм күрсәтү өчен көчләр һәм чаралар җибәрү турында карар кабул итү.

6. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә:

1) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне, шулай ук янгыннарны, алар вакытында барлыкка килү ихтималы булган тискәре нәтиҗәләрне фаразлауны оештыра;

2) гадәттән тыш хәлләрне һәм янгыннарны кисәтү, зыян һәм тискәре нәтиҗәләр күләмен азайту һәм киметү чараларын эшли һәм планлаштыра;

3) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планын эшли;

4) шәһәр территориясендә ГТХТСның ярдәмче системалары һәм звеноларының хәбәр итү һәм килешенгән эш режимын кертә;

5) ГТХТСның идарә органнарын һәм көчләрен әзерләүне, халыкны гадәттән тыш хәл һәм янгын янау яки килеп чыгу шартларында эш итәргә өйрәтүне оештыра;

6) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, сәнәгать һәм икътисадый куркынычсызлыкны тәэмин итү белән бәйле мәсьәләләр буенча карарлар проектларын эшли һәм карау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә кертә;

7) шәһәр территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча ГТХТС звенолары, оешмалар эшчәнлеген контрольдә тота;

8) шәһәрнең башка идарә органнары белән берлектә, потенциаль куркыныч производстволарны урнаштыру һәм аларның эшчәнлеге мәсьәләләрен карап тикшерүдә катнаша;

9) азык-төлекне, азык чималын, азыкны, су чыганакларын һәм су белән тәэмин итү системаларын радиоактив пычранудан (зарарланудан), химик һәм бактериологик (биологик) зарарланудан тиешенчә саклау буенча чаралар күрә;

10) иҗтимагый оешмаларны һәм гражданнарны гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгыннарны профилактикалау чараларын үткәрүгә җәлеп итү эшен оештыра.

7. Комиссия хокуклы:

1) гадәттән тыш хәл вакытында шәһәр территориясендә урнашкан оешмалар һәм гражданнар тарафыннан үтәү мәҗбүри булган карарлар кабул итәргә;

2) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча ГТХТС звенолары, идарә органнары эшчәнлеген контрольдә тотарга;

3) ГТХТС функциональ ярдәмче системалары көчләрен һәм чараларын әзерләүне һәм аларның әзерлеген контрольдә тотарга;

4) шәһәрнең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм эш итү системасына керә торган көчләрне һәм чараларны билгеләнгән тәртиптә кирәкле коткару һәм авария-торгызу эшләрен башкаруга җәлеп итәргә.

8. Комиссия рәисе хокуклы:

1) гадәттән тыш хәл килеп чыгу куркынычы янаганда яисә барлыкка килгәндә, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү эшләрен башкару өчен, билгеләнгән тәртиптә көчләрне һәм чараларны, кемнеке булына карамастан, транспорт һәм матди-техник чараларны җәлеп итәргә;

2) барлыкка килгән шартларга карап, ГТХТС ярдәмче системаларының һәм звеноларының эш режимнарын кертергә һәм туктатырга;

3) хәлнең начараю сәбәпләрен ачыклау һәм аны нормальләштерү буенча тәкъдимнәр кертү өчен, шәһәр территориясендә, идарә органнарын һәм ГТХТС звеноларына керә торган көчләрне әзерләргә һәм районнарга күчерергә.

4) гадәттән тыш хәлләрне һәм янгыннарны бетерүдә катнашучы формированиеләрне матди-техник чаралар белән өзлексез тәэмин итү чараларын оештырырга.

## 3 бүлек. Комиссия составы

9. Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана.

10. Комиссияне Башкарма комитет Җитәкчесе җитәкли.

11. Комиссия хәлнең начараю сәбәпләрен билгеләү һәм ачыклау өчен, гадәттән тыш хәлләрне булдырмау буенча тәкъдимнәр эшләү һәм чаралар күрү, аларның барлыкка килүен һәм катлаулылыгын бәяләү, гадәттән тыш хәлләрне локальләштерү, халыкны һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдимнәрне эшкәртү, һәм бәла-каза районында турыдан-туры күрсәтелгән гамәлләрне һәм чараларны тормышка ашыру өчен оператив төркемнәр формалаштыра.

12. Гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда оператив төркемнәргә, бәла-казалар зонасында хакимият һәм идарә органнары белән берлектә, аларны бетерү буенча эшләр белән җитәкчелек итү йөкләнә. Оператив төркемнәрнең составы, кирәкле белгечләрне җәлеп итеп, комиссия әгъзаларыннан формалаштырыла.

13. Гадәттән тыш хәлләрдә шәһәр оешмалары гадәттән тыш хәлләрне һәм янгыннарны булдырмау һәм бетерү буенча чараларны гамәлгә ашыралар, комиссиянең оператив төркеме җитәкчелегендә эшчәнлек алып баручы оператив төркемнәр бүлеп бирәләр.

## 4 бүлек. Комиссия эшен оештыру

14. Комиссия рәисе комиссиягә йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрнең үтәлеше өчен шәхси җаваплы.

15. Комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлү һәм раслау комиссия рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

16. Комиссия эше комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннанраслана торган айлык һәм еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

17. Комиссия эшчәнлеге даими нигездә гамәлгә ашырыла. Әгәр аларда аның әгъзаларының яртысыннан күбесе катнашса, комиссия утырышлары тулы хокуклы дип санала. Комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

18. Комиссия карары рәис тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2020 елның 14 сентябрендәге
4569 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү
һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе
составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Салахов Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Зуев Илья Сергеевич | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 3. | Зыятдинов Рафаил Хафиз улы | ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 4. | Мингалиев Рәүф Минрәхим улы | комиссия секретаре, Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| комиссия әгъзалары: | | |
| 5. | Альменеева Эльвира Емельяновна | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү бүлеге башлыгы |
| 6. | Анисимов Марат Александрович | «Автомобиль юллары предприятиесе» МУП директоры вазыйфаларын башкаручы, юл хезмәте башлыгы |
| 7. | Бариев Илгизәр Габделхалик улы | Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Росия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең Яр Чаллы шәһәре, Актаныш районы территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 8. | Галимов Искәндәр Нургаләм улы | Башкарма комитетның Үзәк район хакимияте башлыгы |
| 9. | Ганиев Айрат Сәйдәш улы | Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы, инженерлык хезмәте башлыгы |
| 10. | Ибраһимов Ринат Таһир Улы | «Таттелеком» ААҖ филиалы - Яр Чаллы зона электр элемтәсе узелы башлыгы, элемтә хезмәте башлыгы (килешү буенча) |
| 11. | Кәрамиев Румил Рәүф улы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы, мәдәни кыйммәтләрне саклау хезмәте башлыгы |
| 12. | Кислов Александр Иванович | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте башлыгы |
| 13. | Николаев Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе, медицина хезмәте башлыгы (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 14. | Садыйков Данис Илһам улы | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы идарәсенең җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция башлыгы урынбасары, җәмәгать тәртибен саклау хезмәте башлыгы (килешү буенча) |
| 15. | Ситдыйков Салават Әнәс улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 16. | Солтанова Рәисә Кәүсәр кызы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең куллануччылар базары бүлеге башлыгы, сәүдә һәм туклану хезмәте башлыгы |
| 17. | Хәбибрахманов Рәшит Гыйльфан улы | «Татнефть-АЗС Центр» ҖЧҖнең Чаллы филиалы директоры, ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү хезмәте башлыгы (килешү буенча) |
| 18. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, эвакуация комиссиясе рәисе |
| 19. | Харисов Винер Хәмит улы | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте башлыгы |
| 20. | Хуҗин Рөстәм Нияз улы | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы |
| 21. | Шаронов Эдуард Павлович | «Челтәрләр компаниясе» ААҖ филиалы - Яр Чаллы электр челтәрләре директоры, энергетика һәм яктылык маскировкасы хезмәте башлыгы (килешү буенча) |
| 22. | Юмагулов Рөстәм Наил улы | ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең янгынга каршы дәүләт хезмәте федераль янгынга каршы хезмәтенең 15 нче янгын сүндерү-коткару отряды башлыгы (килешү буенча). |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева